

Ел саен августнын икенче шимбәсендә билгеләп vтелә торган Физкультурачы конен безнен миллионлаган ватандашларыбыз vз бәйрәмнәре дип саный.
Бу - һонәренә һәм яшенә карамастан, спортны яратучылар коне. Торбеево бvгенге кондә спорт хәрәкәте ветераннары саклаган спорт традицияләре белән һәрвакыт дан тотты, мәсәлән, Россия Теннис федерациясе президенты Шамиль Тарпищевыбыз. Ә актив яшьләр бу спорт хәрәкәтен дәвам итә. Яшь, ометле спортчыларнын зур когортына сәләтле дзюдочы, пауэрлифтинг буенча бронза яулаган Алина Такташованы да керә.
Торбеево ДЮСШда тренер Владимир Алексеевич Мишинда тәрбияләнvче Алина Такташова пауэрлифтинг буенча Россия беренчелеге призеры булды. Тулада vткән ярышларда Мордовиядән яшь спортчы 14-18 яшьлек кызлар арасында 57 кг. авырлыктагы категориядә оченче урынны яулаган. Ул «классик жим» дисциплинасында 57,5 кг кvтәргән. Үзенен авырлыгыннан 0,5 кг артык кvтәргән. Әйтеп китәргә кирәк, турнирда Россиянен 59 тобәгеннән барлыгы 300гә якын спортчы катнаша, ә регионыбызнын данын бер Алина данлый. Алина Саид кызы Такташованы бу тор спорт буенча Россия жыелмасы-сборные составына кабул иткәннәр.
Алтмыш медаль иясе ундvрт яшьлек Алина Такташова тумышы белән Торбееводан, Торбеевонын икенче мәктәбендә белем ала. Яшь спортчы һәрвакыт тренировкаларга бик теләп йори. Алинанын спорт казанышлары озак коттерми. Ул vзенен Татар-Юнки, әнисе Диляра Динар кызынын туган авылындагы беренче район ярышларын мәнгегә хәтерендә калдыра: анда ул ышанычлы беренчелекне яулый. Республика ярышларына, аннан сон Ботенроссия ярышларына да чыга башлый. Бvген ул Мордовия жыелма командасы составында республика данын яклый, алда - Россия командасы составында.
8 сыйныфны тәмамлаган Торбеево мәктәбе укучысы Алина Такташованы барлык спорт ярышларында әтисе Саид Имать улы Такташов белән турнирга йори. Шунысын да билгеләп vтәргә кирәк, анын топ жанатары – Алинаны барлык ярышларда озатып йорvче әтисе Саид Имать улы (тумышы белән якташ язучыбыз Такташлы Сыркыдыдан); анын белән бергә унышсызлыклар кичерә һәм жинvләргә шатлана. Әлбәттә, ул vзенен талантлы кызы белән горурлана һәм алга таба унышлар тели.
Әйтеп китәргә кирәк, татар жанлы, яратып Юнкидә, Сыркыдысында Аетларны бәйрәм иткән, тырыш һәм булдыклы Торбеево тимер юлы участогы начальнигы Саид Имать улы белән яратып милли ашларыбызны – пәрәмәч, бәлешләребезне пешергән, коллективында хормәт казанган Торбеево тимер юлы кассасы кассиры Диляра Динар кызы Алинага һәм анын апасы Эльвирага тиешле тәрбия биреп vстерәләр. Югары белемле Эльвиралары гаиләсе белән башкалабыз Мәскәvдә яши. Ә Алина бvген vзенен барлык сәләтләрен кулланырга тырыша, спортта яна биеклекләргә ирешv очен коч куя.
Алина белән аралашканда ул әнисе әзерләгән чәк-чәкне һәм пәрәмәчне бик тә тәмләп ашарга ярата. Укудан, спорттан буш вакытларда рәсем ясарга, гитарада уйнарга ярата.
«Бары тик vз-vзенә ышанырга кирәк, шул чакта барысы да килеп чыгачак!» - дип елмаеп кызы турында сойли сәләтле пауэрлифтингчы, дзюдочы Алина Такташованын әтисе Саид Имать улы.

**Наилә НАСЫРОВА**